**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14 нче ноябрь, 2023 ел

**РЕШЕНИЕ**
№32-05

**«Актаныш муниципаль районы территориясендә сатулар үткәрмичә генә аренда шартнамәләре төзегәндә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең процент ставкасын билгеләү турында» 2019 елның 15 апрелендәге 37-14 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясының14 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районы территориясендә сатулар уздырмыйча гына аренда шартнамәләре төзегәндә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең процент ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2019 елның 15 апрелендәге 37-14 номерлы карарына үзгәреш кертергә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. Муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең процент ставкалары күләмнәрен Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә сатулар уздырмыйча гына җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре төзегәндә билгеләргә, әгәр дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре, карар кабул итү датасына кимендә биш ел кала расланса:

- җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән 0,3 процент күләмендә, әгәр җир кишәрлегенең мәйданы 100 гектардан артып китсә, авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару һәм авыл хуҗалыгы файдалануы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен арендага бирү очракларында;
- җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән 1,5 процент күләмендә, әгәр җир кишәрлегенең мәйданы 100 гектардан ким булса, авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару һәм авыл хуҗалыгы файдалануы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен арендага бирү очракларында;
- торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм шәхси ярдәмче хуҗалык өчен файдаланыла торган мондый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 10 проценты күләмендә;
- торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм индивидуаль торак төзелеше өчен файдаланыла торган мондый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 20 проценты күләмендә;
- торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм бакчачылык өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 10 проценты күләмендә.

2. Җир кишәрлегенең кадастр бәясе күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелә торган җир кишәрлегенең кадастр бәясе турындагы белешмәләр нигезендә билгеләнә.
3. Әлеге карарны «Актаныш таңнары» газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов